ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2014 Казан ш. № 4-3/г

***Татарстан Республикасының Газлаштыру программасын финанслау өчен “Газпром трансгаз Казан” ҖЧҖнең газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлау хезмәте буенча тарифларга махсус өстәмә бәяләрнең күләмнәрен 2015 ел өчен билгеләү турында***

1999 елның 31 мартындагы “Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында”гы №69-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 3 маендагы “Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газны транспортлауга карата тарифларга махсус өстәмә түләүләрне билгеләү тәртибе турында”гы №335 карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең 2011 елның 21 июнендәге “Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газны транспортлауга карата тарифларга махсус өстәмә түләүләрне билгеләү методикасын раслау турында”гы №154-э/4 боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге №468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. 2015 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр әлеге карарга теркәлгән кушымта буенча календарь бүлгәләп барлык кулланучылар төркемнәре өчен (халыктан гайре) Татарстан Республикасының Газлаштыру программасын финанслау өчен “Газпром трансгаз Казан” ҖЧҖнең газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлау хезмәте буенча тарифларга махсус өстәмә бәяләрнең 2015 ел өчен күләмнәрен билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылганнан соң ун көн узгач гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2014 ел, №4-3/г боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасының Газлаштыру программасын финанслау өчен “Газпром трансгаз Казан” ҖЧҖнең газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлау хезмәте буенча тарифларга махсус өстәмә бәяләрнең 2015 ел өчен календарь бүлгәләнгән күләмнәре

| Татарстан Республикасында газ бүлүче оешманың аталышы | Ел | Махсус өстәмә түләү күләме, 1000 куб.м өчен сум (НДС исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|
| «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ | 01.01.2015 алып 30.06.2015 кадәр | 30,68 |
| | 01.07.2015 алып 31.12.2015 кадәр | 42,51 |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге